Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Югары Акташ авыл Советы

КАРАРЫ

03 июнь 2022 ел №47

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Акташ авыл Советының 2014 елның 05 ноябрендә кабул ителгән 105 номерлы «Югары Акташ авыл башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук Югары Акташ авыл башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турындагы нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 1 апрелендәге 90-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Югары Акташ авыл Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Акташ авыл Советының 2014 елның 05 ноябрендә кабул ителгән 105 номерлы «Югары Акташ авыл башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук Югары Акташ авыл башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмә хакында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

6 пунктның в) пунктчасында «акцияләрен» сүзен төшереп калдырырга;

13 пунктта «акцияләрен» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Югары Акташ авылы, Совет урамы, 15 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU), «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Югары Акташ
авыл җирлеге башлыгы А.В.Шатунов